ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 131-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 131-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 507-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелә

**«Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» 2024 елның 29 апрелендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2024, № 34 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты махсус хәрби операциядә катнашучы затларга ярдәм күрсәтү йөзеннән эшләнгән.

Закон проектында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган махсус хәрби операциядә катнашучы затларның, хәрби хезмәткәрләр арасыннан булган затларның, ирекле формированиега керү турында контракт төзегән затларның, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче затларның, шулай ук аларның ата-аналары, хатыннары (ирләре), балигъ булмаган балаларының, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлары булуга карамастан, социаль ярдәмнең аерым чараларын алу хокукын 2026 елның 31 декабренә кадәр озайту карала.

**«Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘМӘ**

«Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми, шуның белән бергә күләмен бәяләү мөмкин булмаган алынып бетмәгән керемнәргә китерергә мөмкин.